| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 май г.Казань № 347

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче, 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы, 2010 ел, 9 апрель, 253 нче, 2010 ел, 9 июнь, 454 нче, 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 21 февраль, 125 нче, 2011 ел, 25 март, 220 нче, 2011 ел, 13 апрель, 291 нче, 2011 ел, 29 июль, 613 нче, 2011 ел, 13 август, 674 нче, 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2013 ел, 9 февраль, 80 нче, 2013 ел, 14 март, 163 нче, 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы, 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы, 2014 ел, 5 февраль, 64 нче, 2014 ел, 29 март, 201 нче, 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче, 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы, 2015 ел, 3 июнь, 401 нче, 2015 ел, 20 август, 610 нчы, 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче, 2016 ел, 26 февраль, 121 нче, 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче, 2017 ел, 9 февраль, 74 нче, 2017 ел, 10 июль, 468 нче, 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы, 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы, 2018 ел, 29 март, 185 нче, 2018 ел, 4 май, 317 нче, 2018 ел, 27 июнь, 523 нче, 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы, 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы, 2019 ел, 4 апрель, 270 нче, 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы, 2020 ел, 26 март, 220 нче, 2020 ел, 25 май, 424 нче, 2020 ел, 26 август, 744 нче, 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче, 2021 ел, 4 май, 306 нчы, 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы, 2022 ел, 9 июль, 661 нче, 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче, 2022 ел,

16 ноябрь, 1218 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче, 2023 ел, 14 апрель, 462 нче, 2023 ел, 05 август, 946 нчы, 2023 ел, 06 октябрь, 1252 нче, 2023 ел, 28 декабрь, 1712 нче, 2024 ел, 10 май, 316 нчы, 2024 ел, 06 август, 623 нче, 2024 ел, 04 сентябрь, 724 нче, 2025 ел, 12 апрель, 222 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 пунктның 3.3.18 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.3.18. Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна һәм бюджет учреждениеләрен (алга таба – учреждениеләр), шулай ук коммерциягә карамаган башка оешмаларны (алга таба – оешмалар) гамәлгә куючыларның функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

учреждениеләр һәм оешмалар төзү, аларны үзгәртеп оештыру, аларның типларын үзгәртү, аларны бетерү турындагы карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлегенең учреждение һәм оешмалар эшчәнлеген бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килү-килмәвен бәяли;

учреждениеләрдә һәм оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары бирелгән башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контролендә тотуны гамәлгә ашыра;

учреждениеләргә аларның уставларында каралган төп эшчәнлек төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

учреждениеләрне һәм оешмаларны гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин